**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫН ХӘЛ ИТҮ**

**2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында
Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы
Иске Маврин авыл җирлегенең Иске Маврино торак пунктында**

20.11.2024 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлегенең Иске Маврино торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Иске Маврин авыл җирлеге Иске Маврино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 600 (алты йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, шул исәптән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем Инвалидларыннан, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Төзүчеләр урамы буенча юл асфальтлау (эшләрне дәвам итү).
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) 7 көн дәвамында (Иске Маврин авыл җирлеге Уставының 69 п.5 статьясы) кабул ителгән көннән.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Маврин авыл җирлеге башлыгы Р.Г.Нургалеев